# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“28” ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 28 ноябрендә «Сез 2022 елда Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Төрекләр авыл зираты территориясен чистарту (үлән чабу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- материаллар сатып алу, Төрекләр авылы зиратына койма кую (килешү буенча эшләр өчен түләү).
- территорияне чистарту үлән чабу, (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Яшь Коч урамында ясалма тигезсезлекләр урнаштыру, тиешле юл билгеләре белән билгеләнгән;
- автономияле резерв чыганагы сатып алу (генератор).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 88 (сиксән сигез) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 50 (илле ) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 50 (илле ) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Сез 2022 елда Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Төрекләр авыл зираты территориясен чистарту (үлән чабу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- материаллар сатып алу, Төрекләр авылы зиратына койма кую (килешү буенча эшләр өчен түләү).
- территорияне чистарту үлән чабу, (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Яшь Коч урамында ясалма тигезсезлекләр урнаштыру, тиешле юл билгеләре белән билгеләнгән;

- автономияле резерв чыганагы сатып алу (генератор).

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Низамиев